**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская,
дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы.,
38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 май 2023 №396

**Әтнә муниципаль районында юл сервисы объектларын җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына тоташтыру буенча хезмәтләр исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына юл сервисы объектларын тоташтыру буенча хезмәтләр исемлеген раслау турында " 2017 елның 7 февралендәге 65 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына ярашлы **карар итәм:**

1. Әтнә муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына юл сервисы объектларын тоташтыру буенча хезмәтләрнең бәясен һәм исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Әтнә муниципаль районында юл сервисы объектларын җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына тоташтыру чыгымнарын исәпләү тәртибен расларга (2 нче кушымта).

3. Әтнә муниципаль районында юл сервисы объектларын җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына тоташтырудан алынган акчалар Әтнә муниципаль районының җирле бюджетына күчерелә.

4. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф.Каюмов